РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВАРЯШ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВӘРӘШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**КАРАР № 1**

Вәрәшбаш авылы “15” январь 2024 ел.

**Вакытлыча кар өю урыннарын билгеләү турында**

Интенсив кар яву чорында юлларны һәм урамнарны вакытында чистартуны тәэмин итү, 2024 елның кышкы чорында Вәрәшбаш авыл җирлегендә территорияне җыештыруны тәртипкә салу һәм вакытлыча кар өю урыннарын билгеләү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, “Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә , Мөслим районы прокурорының 2024 елның 11 гыйнварындагы 02-08-02-2024 номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, Вәрәшбаш авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның кышкы чорында карны вакытлыча тоту өчен ачык мәйданчыклар сыйфатында түбәндәге территорияне билгеләргә:

- кадастр номеры 16:29:070402:41 булган җир кишәрлеге янәшәсендә Вәрәшбаш авылы янында урнашкан бушлык;
- кадастр номеры 16:29:070102:108 булган җир кишәрлеге янәшәсендә Иске Вәрәш авылы янында урнашкан бушлык.

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм ТР Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **З.З.Галиева**